ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Яшьләр һәм Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәте турында” Татарстан Республикасы Законының 11$^1$ статьясына үзгәреш кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2017 елның 21 мартында
кабул ителде

**1 статья**

“Яшьләр һәм Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәте турында” 1993 елның 19 октябрендәге 1983-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 11$^1$ статьясындагы сигезенче өлешенә (2005 елның 26 маендагы 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993, № 10; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 5; 2009, № 6; 2012, № 6 (I өлеш); 2013, № 4 (I өлеш); 2014, № 1 – 2; 2016, № 7 – 8), “дәүләт яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру буенча федераль башкарма хакимият органына” сүзләрен “федераль башкарма хакимиятнең дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү һәм дәүләт мөлкәте белән идарә итү функцияләрен гамәлгә ашыручы органына” сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2017 ел, 05 апрель
№ 17-ТРЗ